КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 27 апрель г.Казань № 285

2024 елда Татарстан Республикасында оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләре (оешмалары) ихтыяҗлары өчен һөнәри укытуны һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2024 елда Россия Федерациясе субъектларының хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны гамәлгә ашыру буенча «Демография» илкүләм проектының «Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган төбәк проектларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында 2024 елда Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 2021 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2024 елда оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләре (оешмалары) ихтыяҗлары өчен уку-укытуны оештырганда «Демография» илкүләм проектының «Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган төбәк проектларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республликасы бюджетына субсидияләр рәвешендә бирелә торган акчалардан файдалану тәртибен;

2024 елда эш бирүчеләрнең оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләре (оешмалары) ихтыяҗлары өчен уку-укытуны оештыруга чыгымнарын финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен эш бирүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидияне бирү тәртибен.

2. Бу карарны куллану буенча аңлатмалар Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2022 – 2023 елларда Татарстан Республикасында сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру турында» 2022 ел, 23 март, 257 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда Татарстан Республикасында сәнәгать предприятиеләренең эштән азат ителү рискындагы хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру турында» 2022 ел, 23 март, 257 нче карары белән расланган 2022 елда сәнәгать предприятиеләренең эштән азат ителү рискындагы хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча эш бирүчеләрнең чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен эш бирүчеләргә субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 ел, 7 декабрь, 1300 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елларда Татарстан Республикасында сәнәгать предприятиеләренең эштән азат ителү куркынычындагы хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру турында» 2022 ел, 23 март, 257 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 ел, 18 февраль, 157 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2023 елларда Татарстан Республикасында сәнәгать предприятиеләренең эштән азат ителү куркынычындагы хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру турында» 2022 ел, 23 март, 257 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 ел, 24 апрель, 522 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2023 елларда Татарстан Республикасында сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру турында» 2022 ел, 23 март, 257 нче карары белән расланган 2022 – 2023 елларда сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләрен һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча эш бирүчеләрнең чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен эш бирүчеләргә субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2023 ел, 24 август, 1009 нчы.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин